| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«СТАРОКУВАКСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ИСКЕ КУАК<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның 31 июле № 1

Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлегенең Иске Куак авыл торак пунктында гражданнар җыенының 2024 елның 22 ноябрендәге 3нче, 4нче номерлы карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (29.11.2023 №1532 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының 2025 елның 20 июнендәге 34 номерлы «Лениногорск муниципаль районы авыл җирлекләре бюджетларына 2025 елда кергән гражданнарның үзара салым акчаларын финанслашу турында» карары белән, Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлегенең Иске Куак авыл торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту, Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлегенең Иске Куак авыл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 23 ноябрендәге 3 номерлы һәм «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлегенең Иске Куак авыл торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында» 2024 елның 22

ноябрендәге 4 номерлы карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2025 елның 12 августына 16 сәгать 00 минутта билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлегенең Иске Куак авыл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 23 ноябрендәге 3 номерлы һәм «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлегенең Иске Куак авыл торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында» 2024 елның 22 ноябрендәге 4 номерлы карарларын түбәндәге эчтәлекле 4) пункт белән тулыландыру белән килешәсезме:

«3) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Иске Куак авылындагы Җиләкле урамындагы юллардагы чокырларга таш түшәп ремонтлау; Иске Куак авылындагы юлларны кардан чистарту)» һәм алынган акчаларны югарыда күрсәтелгән мәсьәләне хәл итүгә юнәлтергә.

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иске Куак авылы, Заварыкин урамы, 36 йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Иске Куак авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы И.Н.Сушкова